КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 апрель г.Казань № 514

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 август, 820 нче карары белән теркәлгән Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оештыруга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оешты-руга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау

турында» 2022 ел, 15 август, 820 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 19 декабрь, 1369 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оештыруга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин